**СОВЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 с..Нармонка,
Ул.Молодежная, д.12 А
тел.8-(84378)4-62-24
факс: 8-(84378)4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422630 Нармонка авылы,
Яшьләр урамы, 12 а нчы йорт,
тел.8-(84378)4-62-24
факс: 8-(84378)4-62-24

---

**2020елның «21» сентябре** **5 номер**

# КАРАР

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башлыгының, Нармонка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата түләүләре күләмен арттыру турында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» ТР МКның 2020 елның 6 августындагы 658-р номерлы карары нигезендә 2020 елның 1 октябреннән муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында контроль-хисап органы рәисенең айлык акчалата түләүләре күләмен 1,03 тапкырга арттырырга:

1. Нармонка авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " 2018 елның 13 апрелендәге 100 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.
2. Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 11 апрелендәге 103 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтнең алар биләгән вазыйфалары нигезендә Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Лаеш муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Л.Д.Стерякова**